**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

# Об отмене ограничительных мероприятий (карантина), установленных на отдельной территории Кадряковского сельского поселения муниципального образования «Агрызский муниципальный район Республики Татарстан» в связи с ее неблагополучием по заболеванию бешенством животных

В связи с истечением 60 календарных дней после уничтожения последнего трупа больного восприимчивого животного и проведением противоэпизоотических и профилактических мероприятий, в соответствии со статьей $3^1$ Закона Российской Федерации от 14 мая 1993 года № 4979-I «О ветеринарии» **постановляю**:

1. Отменить ограничительные мероприятия (карантин), установленные в связи с неблагополучием по заболеванию бешенством животных на территории личного подсобного хозяйства по улице Заречная, дом 18, села Кадряково в Кадряковском сельском поселении муниципального образования «Агрызский муниципальный район Республики Татарстан» и территории радиусом 1,9 км от границ эпизоотического очага в Кадряковском сельском поселении муниципального образования «Агрызский муниципальный район Республики Татарстан».

2. Признать утратившим силу Указ Раиса Республики Татарстан от 1 ноября 2025 года № 901 «Об установлении ограничительных мероприятий (карантина) на отдельной территории Кадряковского сельского поселения муниципального образования «Агрызский муниципальный район Республики Татарстан» в связи с ее неблагополучием по заболеванию бешенством животных».

3. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

ОБЩИЙ ОТДЕЛ

**Раис**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
05 января 2026 года
№ 6

**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Кадрәк авыл җирлегенең аерым территориясендә хайваннар котыру авырулы булганга, аның имин булмавы сәбәпле кертелгән чикләү чараларын (карантинны) бетерү турында**

Котыру чиренә бирешүчән соңгы авыру хайванның үләксәсе юкка чыгарылган көннән 60 календарь көн узуы, эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар уздырылу белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Кадрәк авыл җирлеге Кадрәк авылындагы Елга аръягы урамы 18 нче йортта урнашкан шәхси йорт хуҗалыгы территориясендә һәм «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Кадрәк авыл җирлегендә урнашкан, эпизоотия чыганагы чикләреннән 1,9 км радиустагы территориядә хайваннар котыру авырулы булганга, аларның имин булмавы сәбәпле кертелгән чикләү чараларын (карантинны) бетерергә.

2. Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Кадрәк авыл җирлегенең аерым территориясендә хайваннар котыру авырулы булганга, аның имин булмавы сәбәпле чикләү чаралары (карантин) кертү турында» 2025 елның 1 ноябрендәге 901 номерлы Указы үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ • АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2026 ел, 05 гыйнвар
№ 6